ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31 03 2021 г. № 77

Гражданнар һәм алар белән даими яшәүче аларның гаилә әгъзалары кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатларында, гражданнар һәм алар белән даими яшәүче аларның гаилә әгъзалары кеременең максималь күләмен билгеләргә:

1.1. Ялгыз кеше өчен – 32 895,46 сум;

1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 20 933,48 сум;

1.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 17 942,98 сум.

2. Гражданнар һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының салым салынырга тиешле мөлкәтләре бәясен билгеләргә:

2.1. Ялгыз яшәүче кеше өчен – 1 949 904,00 сум;

2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2 481 696,00 сум;

2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 3 190 752,00 сум;

2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 4 254 336,00 сум;

2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 5 317 920,00 сум.

3. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2020 елның 3 мартындагы 60 номерлы «Гражданнар һәм алар белән даими яшәүче аларның гаилә әгъзалары кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге башлыгы Е.С. Митрошенковага йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Салаватов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881